**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**Чираттан тыш утырыш дүртенче чакырылыш**

**28 ноябрь 2024 ел** **№151** **Иске Җөри авылы**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2016 елның 10 июнендәге 31 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 8 августындагы 232-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2016 елның 10 июнендәге 31 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары ( 16.05.2017 №57, 03.06.2017 №58, 20.12.2017 №82, 20.12.2018 №132, 06.02.2019 №133, 03.09.2019 №147, 12.03.2021 №14, 15.11.2021 №37, 10.03.2022 №51, 16.01.2023ел №83, 01.11.2024 №142 карарлар редакциясендә) белән расланган, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы – муниципаль берәмлек уставы нигезендә һәм җирле үзидарә органы яки муниципаль вазыйфа биләүче зат вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән вазыйфалар нигезендә барлыкка килә торган, җирле үзидарә органындагы вазыйфа».

1.2. 2 бүлекнең 2 пунктындагы 2 абзацында «муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләренә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 5 бүлекнең 3 пунктының 5 пунктчасында «квалификация турында» сүзләрен өстәргә;

1.4. 4 бүлекнең 1 пунктының 5 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5. 19 бүлекнең 8 пунктында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 28 бүлекнең 1 пунктындагы 1 пунктчасының 4 абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Иске Җөри авыл җирлегенең 2024 елның 1 ноябрендәге 142 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2016 елның 10 июнендәге 31 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Иске Җөри авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Мараков